Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422071, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КИЛДЕБӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы
Килдебәк авылы, Кооператив
урамы, 20а йорт
тел. 45-5-50

Kilb.sab@tatar.ru

27.02.2019 № 5

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитетының
«Килдебәк авыл җирлеге территориясендә
муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда
тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын
раслау турында " 2016 елның 4 маендагы
17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Район прокуратурасының 18.02.2019 №02-08-02-34-2019 протесты һәм 2018 елның 27 декабрендәге 558-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп төзүне һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" гы Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитетының «муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 4 маендагы 17 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.1 пунктның 4 пунктчасында “әлеге йортта гомуми милекне агымдагы һәм капиталь ремонтлау тәртибе” сүзләреннән соң “күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп төзүне гамәлгә ашыру тәртибе таләпләрен бозу фактлары турында” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/kildebiak бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Заһидуллинга йөкләргә.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы: Н. Н. Заһидуллин